күп профильле
18 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

# Мәктәп яңалыклары...

4 нче чыгарылыш
27 нче декабрь

БУ САНДА:

Яңа ел, белән! 1

Яңалыклар 2

«Яңа ел бизәкләре» кул эшләре күргәзмәсе. 3

Тарихи даталар 4



## ЯНА ЕЛ!

*Яңа еллар килсен бәхет алып,*
*Яңа еллар килсен елмаеп.*
*Күңелләрдә мәңге шатлык булсын,*
*Табыннар тулып торсын!*
*Яңа ел белән!*
*Яңа ел белән!*

## 1 нче декабрь -
## Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне



**1 нче декабрь** - Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы игълан иткән Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне. Бу көн ВИЧ – инфекциясе таралуын һәм ВИЧ – инфекция эпидемиясенең афәтле нәтиҗәләрен киметү өчен авыру турында халыкның хәбәрдар булырга тиешлеген искәртү көне булып тора. Бу дата ел саен бөтендөнья җәмәгатьчелеген ВИЧ – инфекциясе турында онытмыйча, бу авыруны йөртүче кешеләргә сабырлык күрсәтергә дә чакыра.



## «Хорлар ярышы»

**15-17 нче декабрь** көнне актлар залында “**Хорлар ярышы”** уздырылды.

1-8 сыйныф укучылары туган як, дуслык турында рус, татар, инглиз телләрендә җыр башкардылар.

Укучылар бик тырышып әзерләнгән иделәр. Чыгышлар бик эчтәлекле, матур яңгырадылар.

## Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү

Безнең 181 нче мәктәптә юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү буенча системалы рәвештә эшләр алып барыла. Бу айда мәктәпкә “Юл хәрәкәте иминлеге” дәүләт бюджет оешмасының җитәкчесе һәм инспекторлар катнашында Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү көне билгеләп үтелде.



**Декабрь аенда «Яңа ел бизәкләре” дигән күргәзмә оештырылды. Башлангыч сыйныф укучылары бик матур кул эшләре алып килгәннәр иде.**



## 9 декабрь – Ватан Геройлары көне



**РФ Дәүләт Думасы кабул иткән карар нигезендә, РФ Геройларын гына түгел, шулай ук, Советлар Союзы, Социалистик Хезмәт Геройларын, Изге Георгий һәм Дан орденнары кавалерларын да хөрмәтлибез бу көнне.**

**Мондый бәйрәм өчен 9 декабрь очраклы гына сайланмаган. Екатерина II нәкъ менә бу көнне 1769 елда яңа бүләкне раслый. Ул Изге Георгий Победоносец ордены була. Аның белән аерым батырлык күрсәткән сугышчылар бүләкләнгән. Россиядә бу көнне чын батырларны искә алып, алар турында хәтер яңарталар. Ватан Геройлары көне 2007 елдан бирле билгеләп үтелә.**

## Мәскәү өчен сугыш

**30.09.1941-20.04.1942**

**Илнең төньяк башкаласы артыннан беренче, төп башкаланың чираты да килеп җитә. СССРның иң зур, иң абруйлы шәһәре – Гитлер өчен кыйммәтле ташка тиң. Национал-социализмның (Гитлерның идеологиясе нәкъ менә шулай аталган) таҗында бу таш, һичшиксез, урын алырга тиеш. Советлар Союзын бик тиз арада тезләндерү максатыннан башкарылган «Барбаросса» яулап алу планы Мәскәүне кулга төшерүне үзенең төп бурычы итеп куя.**

**Мәскәү өчен сугышны ике этапка бүлеп карау дөрес. Беренче этапта совет армиясе башкаланы дошманга бирдертмәү өчен бар көчен, бар осталыгын, бар ресурсларын эшкә җигеп стационар корылмалар, ныгытылган позицияләрдә саклану сугышы алып барган булса, икенче этапта инде бераз хәл туплаган гаскәр немецларны Мәскәүдән мөмкин кадәр ераграк куарга тырыша.**

**Беренче этап барышында гитлерчыларның һөҗүме бик көчле була, хәрби вәзгыять үтә кискенләшә. Дошман аерым бер позицияләрдә фронт линиясен өзеп, башкалага максималь якын килә. Нәкъ менә шушы вакытта (1941 елның октябрь-декабрь айлары) планлаштырылган гамәлләргә халыкның, җитәкчеләрнең паникасы кушыла. Планлаштырылган гамәлләр дигәндә завод-фабрика, фәнни оешмаларның, җитәкчелекнең эвакуациясе, дошманга калдырмас өчен шәһәрне мөмкин кадәр юк итү күздә тотылган. Ләкин шәһәрлеләргә алдан әйтеп куймау сәбәпле Мәскәүдә паника, халыкның башкаладан качуы башлана. Ике-өч ай эчендә Мәскәү халкы сан ягыннан 4,5 млн.нан 2,5 млн.га кала. Шулай да түзәләр. Әкренләп-әкренләп булса да, һөҗүм дулкыннары сүлпәнәя, ниһаять, туктап кала.**

**Тихвин һәм Ростов операцияләреннән соң инде өченче сизелерлек җиңелүгә дучар булган дошманның югалып калуын ачык сиземли СССР хәрби җитәкчелеге. Бу хәлдән файдаланып та калмакчы булалар – Мәскәү өчен сугышның икенче, һөҗүм этабы башлана. Нәтиҗә: башкаладан берничә дистә чакрымга кадәр килеп җиткән дошман 100-250 км ераклыкка кадәр кире чигерелә, беренче булып атакага бару инициативасы Германиядән СССРга күчә.**

**Мәскәүне саклаганда 926 519 кеше һәлак була, 879 879 ы яралана, өши һәм авырып китә.**

**Тулпар урамы, 2нче йорт**
**Телефон: 89050229576**
**Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru**
**Редколлегия:**
**Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Закирова Азалия**
**Җитәкчесе: Габдуллаҗанова А.Ф.**